РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.12.2022

КАРАР
№18

Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның естәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләтүгә еметсез дип танылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны һәм бурычларны бетерү тәртибен һәм түләтүгә еметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 02.04.2019 ел №ММВ-7-8/164@ боерыгының 6 пункты нигезендә, Олы Шыңар авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча түләнеп бетмәгән салымнарны һәм бу салымнарның пенялары буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән тешерүгә еметсезлекне тануның естәмә нигезләрен (алга таба – бурыч) билгеләргә:

-балалар йортларында һәм балалар өчен приютларда тәрбияләнүче, әти-әниләре Ата-ана хокукыннан мәхрүм калган балигъ булмаган гражданнар;

-физик зат вафат булган кеннән яисә аны Россия Федерациясенең Граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан иткәннән соң, барлык варислар мирас хокукыннан баш тарткан очракта, варислар булмаганда яки мирасны кабул итмәгән очракта, өч еллык срок узу;

-салым түләүченең бөлгенлеккә төшүе (банкротлык) турында эштә кулланыла торган процедураларда табылмавы шарты белән, физик затларның җирле салымнар буенча пенялар буенча бурычлары һәм (яки) өч еллык срогы чыккач, аларның күләме 100 сумнан артмый;

-«Белгенлеккә тешү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп – хисапларны тәмамлау йомгаклары буенча түләнмәгән һәм күрсәтелгән Федераль законның 5 статьясы нигезендә агымдагы түләүләргә караган пенялар буенча бурычлар елешендә гражданны банкрот дип тану.

2. Салым түләүченең бурычын исәптән төшерү әлеге карар, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10нчы номерлы районара ИФНСы тарафыннан бирелгән салым түләүченең бурычы турында белешмә һәм Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны һәм бурычларны бетерү тәртибен раслау турында» 02.04.2019 ел №ММВ-7-8/164@ боерыгында күрсәтелгән документлар, Олы Шыңар авыл башкарма комитеты тарафыннан салым органына тапшырылган, түләтүгә өметсез дип табылган, түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеге нигезендә салым органы тарафыннан башкарыла

3. Татарстан РеспубликасыСабамуниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының «җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымнарны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә еметсез дип тануның естәмә нигезләре турында»гы 17.07.2017 ел №14 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ shinar адреслары буенча бастырып чыгарырга.

5. Карарның үтәлешен тикшерүне үз естемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов